**Республика Татарстан**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 47, с. Муртыш-Тамак
423358
Телефон: 4-52-05

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 47 йорт, Мортыштамак авылы,
423358
Телефон: 4- 52-05

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 9 ноябре** **16 номерлы**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 27 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ Федераль законның 1 статьясы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы, Россия Федерациясе Җир Кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 27 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану яисә җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2.6 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында мондый җир кишәрлеге турында белешмәләр булганда);».

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 27 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Территорияләрнең кадастр планында җир кишәрлеге яисә җир кишәрлекләре схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 3 бүлекнең 1-32 нче кушымталарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә

административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлек гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү вариантларын үз эченә алырга тиеш;».

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 27 декабрендәге 14 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген түләүсез вакыты чикләнмәгән файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.1. 1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2. 1 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адрес буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе — И. Н. Һадиуллин